**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**

Азнакай шәһәре №328-45 «12» март 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль район Советының 2012 елның 15 мартындагы 117-18 номерлы «Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә һәм (яки) җирле халык мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибе турында» карары белән расланган Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә һәм (яисә) җирле халык мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2017 елның 29 сентябрендәге 136-21 номерлы, 2019 елның 20 аввустындагы 282-38 номерлы карарлар редакциясендә)

2019 елның 27 декабрендәге 477-ФЗ номерлы "Җирләрне мелиорацияләү турында "Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль закон һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итә:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль район Советының 2012 елның 15 мартындагы 117-18 номерлы «Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә һәм (яки) җирле халык мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибе турында "карары белән расланган Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә һәм (яисә) җирле халык мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибе турындагы нигезләмәгә (2017 елның 29 сентябрендәге 136-21 номерлы, 2019 елның 20 аввустындагы 282-38 номерлы карарлар редакциясендә) (плга таба – нигезләмә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. нигезләмәнең 1 бүлегендәге 3 пунктының 4 пунктчасында "дренажлы" сүзләреннән соң "һәм мелиоратив" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге үзгәрешләр 2020 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru к

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Азнакай район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләнә.

Рәис М. З. Шәйдуллин